

Ирек Назыл улы Хусаинов унынчы сыйныфка кадәр 1 нче номерлы Ләмберә урта мәктәбендә укый, аннары 32 нче санлы Саранск мәктәбенә кvчә. Җәй коне ул, башка егетләр белән бергә, Пенза хәрби училищесы каршындагы хәрби лагерьга китә. Нәкъ менә шунда ул хәрбилек - анын тормыш сәләте булуын анлый да инде. Әлбәттә, армия тормышы – шикәр тvгел, шуна да карамастан, мәктәптән сон Казан югары танк командасы - Кызыл Байрак орденлы Жуков училищесына укырга керергә карар кыла. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, әлеге уку йорты диварларыннан исемнәре яхшы билгеле булган кvп кенә танылган офицерлар чыга. Бу, Россия Кораллы кочләренен ботен команда составы диярлек... Конкурс зур иде: 670 кешенен нибары 130 гына сайлап алырга тиеш иделәр. БДИнын баллары, гомуми физик әзерлек, хәрби хезмәт белән берлектә, укырга керvчеләрнен психологик хәле исәп кә алынды. Шулай да Мордовиядән килгән Ирек, каты конкурсны vтеп, курсант була.

- Менә, ялга кайттым, туганнарымны бик кvрәсе килде! – ди Ирек курсант.
Ул мәктәптә спорт белән мавыга: беренче олкәннәр разряды ала. Ярышларда катнаша. Сәламәт яшәv рәвеше алып бару, тормыш юлын сайлауда да ярдәм итә.
- Әлбәттә, физик чыныгу ярдәм итте, - дип сойли Ирек. - Суркинодан Руслан Карабанов адресына да ин жылы сvзләремне әйтәсем килә. Ул мина, якташым буларак, бик кvп ярдәм итте. Руслан быел училищены тәмамлады һәм хәзер Тvбән Новгород олкәсендә хезмәт итә. Без анын белән гел элемтәдә торабыз. Мина килгәндә, укырга оч ел калды. Мәктәпне тәмамлаганнан сон «танк бvлекчәләре белән идарә итv, танк взводы командиры» («управление танковыми подразделениями, командир танкового взвода») белгечлеге һәм офицер исеме лейтенант алам. Тагын шунсы ошый, училищеда хәрби исем генә бирмиләр, остәмә рәвештә без оч югары белем алабыз: инглиз теленнән тәржемәче, психолог һәм менеджер. Язмыш ничек килеп чыгасын кем белә, бәлки, боларнын барысы да киләчәктә кирәк булыр. Училищеда гуманитар фән- нәр кафедрасы эшли. Остәвенә, икътисади белем бирелә. Тормышта боларнын барысы да артык булмас. Әлбәттә, vз авырлыклары да бар, тик алар кайда гына булмый! Бирелә яхшы белем алам, плюс, офицер погоннары. Бу минем киләчәккә планнарым. Ихтыяж зур булган белгеч булу - безнен коннәрдә vз сәләтенне һәм момкинлекләренне тулырак гамәлгә ашы- ру очен кирәк.

**Наилә НАСЫРОВА**